# Мәчетләр каршындагы курсларда фикһ дәресләрен укыту методлары



## *Гыйбадәтнең шәхескә булган тәэсире*

1) Кешенең күңелендә иманның (гакыйдәнең) ныгуы.

2) Кешене тәрбия итүе, пакълавы һәм дөрес булган яшәү рәвешенә юнәлдерүе.

3) Эзлекле (бер–бер артлы) күтәренке көчне арттыру, үз–үзенә тугрылыклы булуга китерү, калебенең тыныч булуына алып бару.

4) Әхлакның ныгуы, артуы һәм аны үзгәрүдән, түбәнгә төшүдән саклавы.

# ***Гыйбадәтне укытуның методлары***


1 – Әгәр без намаз, зәкят, хаҗ, ураза хакындагы дини китапларны карап чыксак, алар хакындагы мәгълүмат үз эченә түбәндәге 4 якны ала:

- 1) телдәге һәм шәригатьтәге аңлатмасын;
- 2) әһәмиятен, өстенлекләрен, башкаруының әҗерен һәм калдыруның хөкемен;
- 3) аларны башкару рәвешләрен һәм алар хакындагы аятьләрнең аңлатмаларын;
- 4) аның хикмәтен (максатларын һәм файдаларын).

Гыйбадәт дәресләрен укытканда шушы дүрт якны да үтәү бик мөһим:

- Беренчесенә (телдәге һәм шәригатьтәге аңлатмасына) һәм икенчесенә (әһәмияте, өстенлекләре, башкаруның әҗере һәм калдыруның хөкеме), кереш өлеше буларак, артык күп вакыт сарыф итү кирәк түгел;
- өченчесе исә (башкару рәвешләре), укытуның төп өлеше булып, төгәл аңлатып бирүгә мохтаҗ була; бу өлешне укытканда фәкыйһ галимнәрнең фикерләренә тирән кереп китү кирәк түгел, алар арасындагы каршылыклы фикерләргә тукталмаска; киресенчә, мөгаллимгә аларны башкару рәвешләрен аңлаешлы аңлатып бирү кирәк;

– дүртенчесе исә (хикмәте: иңдерүнең максатлары һәм файдалары,) иң әһәмиятлесе була, чөнки ул гыйбадәт итүнең рухи, тәэсир итүче өлеше.



2- Гыйбадәт дәресләрен гамәли рәвештә алып бару бик мөһим.

3 – Ханәфи мәзһәбенә нигезләнгән рәвештә алып бару.

4 – Көндәлек тормыштан, төрле вакыйгалардан мисаллар китерү, булырга мөмкин булган проблемалар белән таныштыру һәм хәл итү юллары белән таныштыру.

5 – Татарлар арасында киң таралыш тапкан булган китаплар белән таныштыру, мәсәлән «Һидая» Б.Маргинани, «Әт-тәсһил әд-дуруури ли-мәсәил әл-кудури».

6 – Гыйбәдләрне башкаруда кайбер үзенчәлекләрнең булуына ишарә итү, мәсәлән җәй вакытларында ястү намазының кермәве, намаз укыганда ирләргә башларын каплавы, читекләрнең таралган булуы һ.б.

7 – Татар галимнәре язган хезмәтләр белән таныштыру яисә шуларның барлыгын әйтү, мәсәлән Әхмәдһади Максудиның «Гыйбадәте исламия» китабы, Габдрахим Утыз–Имәни әл–Болгари, Ш.Мәрҗәни, Муса Бигиев әсәрләре һ.б.

8 – Гыйбадәтнең:

– татар халкының иҗатына тәэсир итүе (мөнәҗәтләр, бәетләр, шамаил сәнгате),

– язма әсәрләрдә чагылуы (мәсәлән, Бәдәвам китабы),

– татар язучыларының һәм шәгыйрьләренең әсәрләрендә чагылуы (мәсәлән Мөхәмәдьяр, Г.Тукай һ.б.).

